| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

«11» декабрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 400

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»
2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә Алабуга муниципаль районы Советының 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен;

- әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү урынын Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресында урнашкан Совет бинасында, 2025 елның 10 гыйнварына 14.00 сәгатькә билгеләргә.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне һәм проект буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына кергән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм алга таба раслау өчен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы утырышы каравына чыгарырга.

5. Әлеге карарны һәм теркәлгән кушымталарны «Новая Кама» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Алабуга муниципаль берәмлегене сайтында городелабуга.рф адресы буенча урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Советының 2024 елның
11 декабрендәге 399 номерлы карарына
1 нче кушымта

# АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ

№ _ «__»________20__ ел

**Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә һәм гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2020 елның 29 июлендәге 491 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә.
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
3. Әлеге карарны «Новая Кама» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Алабуга муниципаль берәмлегене сайтында городелабуга.рф адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына үзләренең хокукый актларын әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Советының
2024 елның 11 декабрендәге 399 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. «Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында:

1) 1 өлешнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү;».

2) 1 өлешнең 32 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32)Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук су объектларыннан рекреация максатларында файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

2. «Аның составына керүче авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге» 6.1 статьясындагы 1 өлешенең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итү дә керә, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

3. «Районның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү» 8 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнары тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен, Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә гамәлгә ашыру өчен җаваплы.»;

4. «Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 38 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядәге 10.1 пункты белән тулыландырырга:

«10.1. аларга чит ил агенты статусы алу;».

5. «Район башлыгы вәкаләтләре» 42 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядәге 23.1 пункты белән тулыландырырга:

«23.1) район бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап буенча гавами тыңлаулар билгели;».

6. «Район Башкарма комитетының вәкаләтләре» 47 статьясында:

1) 1 өлешнең 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әйләнә-тирә мохитне саклау буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар нигезендә тиешле муниципаль район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү;».

2) 1 өлешнең 30 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итүне дә кертеп, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү:».

7. «Җирлек Башкарма комитетының вәкаләтләрен үтәү буенча районн Башкарма комитеты вәкаләтләре» 48 статьясында:

1) 1 өлешнең 3 пунктындагы җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра;»;

2) 1 өлешнең 3 пунктындагы сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесе вәкаләтләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итүне, су объектларыннан рекреация максатларында файдалану кагыйдәләрен билгеләүне дә кертеп, гамәлгә ашыра;».

3) 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядәге абзац белән тулыландырырга:

«-әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыра һәм җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыра.».

4) 1 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядәге абзац белән тулыландырырга:

«-шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмчехуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала;».

8. «Районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү» 80 статьясын түбәндәге редакциядәге 5 өлеш белән тулыландырырга:

«5. Җирле үзидарә органнары муниципаль милектәге электр челтәре оешмасы яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эшләүче территориаль челтәр оешмасы яисә территориаль челтәр оешмасы системасындагы электр энергетикасы турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

9. 91 статьяда:

1. статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы органнар вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелек), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контроль оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

2. 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.».

Татарстан Республикасы Алабуга<br>муниципаль районы Советының 2024 елның<br>11 декабрендәге 399 номерлы<br>карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу**
**тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча яисә 3-82-52 язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы формасында түбәндә бирелгән үрнәк нигезендә кертелә:

| N т/б | Тәкъдимнәр кертү инициаторы | Кертеп кую датасы | Абзац, пункт, өлеш, статья, | Проект тексты | Тәкъдимнәрнең эчтәлеге | Кертелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, проектның эчтәлеге; | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын күрсәтеп, язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы карары проекты рәсми басылып чыккан көннән 2025 елның «09» гыйнварына кадәр эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресына яисә почта аша (конвертка «Устав турында фикер алышу» яки «Халык тыңлаулары» тамгасы белән), шулай ук факс буенча 3-82-52 гаризалар бирелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм тиешенчә гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Алабуга
муниципаль районы Советының 2024 елның
11 декабрендәге 399 номерлы карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2009 елның 23 июнендәге 232 номерлы карары белән расланган һәм «Новая Кама» газетасында 2009 елның 19 августындагы 129 номерында басылып чыккан Алабуга муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектына таянып гавами тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар) үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча язма гариза биргән затлар үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукына ия гавами тыңлауларда катнашалар.

Әлеге тәкъдимнәрне кабул итүче органга тәкъдимнәр кергән көн кабул итү датасы булып санала.

3. Гавами тыңлауларында чыгыш ясау хокукы булмаган районның барлык кызыксынган кешеләре дә катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулары башланганчы 30 минут алдан башлана.

5. Халык алдындагы гавами тыңлауларда район Башлыгы, район Башлыгы урынбасары, район Советы рәисе урынбасары, район Советының даими комиссияләре рәисләре, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район Башлыгының вәкаләтле затлары рәислек итә.

6. Гавами тыңлаулары рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, рәис тәкъдиме буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен җитәкче һәм секретариатның ике әгъзасы составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Чыгышларның эзлеклелеге һәм вакыты, карала торган мәсьәләнең эчтәлеген, гавами тыңлауларда катнашу өчен кергән язма гаризаларның санын

исәпкә алып, гавами тыңлаулар уздыру регламенты белән, чыгыш ясау хокукы һәм башка мәсьәләләр белән билгеләнә.

9. Гавами тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

10. Гавами тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау гавами тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны бүлдерергә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклары юк.

11. Рәислек итүче гавами тыңлаулар алып бара һәм көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу тәртибен күзәтә, кирәк булганда, утырышлар залыннан сораулар буенча фикер алышу тәртибен бозучыларны чыгарып җибәрү буенча чаралар күрергә хокуклы.

12. Гавами тыңлаулар вакытында беркетмә алып барыла. Гавами тыңлауларында катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм гавами тыңлаулары беркетмәсенә теркәлә.

13. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имза сала һәм район Советында саклана.

14. Мәҗбүри йомгаклау документы булып, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә тора, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында гавами тыңлаулар үткәргәннән соң өч көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга һәм урнаштырырга тиеш.

15. Гавами тыңлауларны оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Алабуга муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.